ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » __05__ 2025 ел Мөслим № 254

**«2025 елга Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2024 елның 23 декабрендәге 565 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында һәм хезмәт күрсәтүләр күләменең расланган нормативлары нигезендә балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру программасы кысаларында үткәрелә торган чаралар графигына үзгәрешләр кертү, балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составын үзгәртү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2025 елга Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2024 елның 23 декабрендәге 565 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2025 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ял программасы» Карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә»;

1.2. «2025 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ял итү программасы» Карарының 4 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм 2 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә»;

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия рәисе, Мөслим муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль һәм мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Салихҗанов

Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 21 маендагы 254 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составы**

Бәдретдинова М.Р. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары - ***комиссия рәисе***;

Хәбибуллина Л.Я. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының мәгариф идарәсе башлыгы - ***комиссия рәисе урынбасары;***

Җаббаров И.Р. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге башлыгы - ***комиссия рәисе урынбасары***;

Бәдртдинов А.К. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ директоры - ***комиссия рәисе урынбасары***;

Морзаханова Ф.Г. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ методисты - **комиссия секретаре.**

***Комиссия әгъзалары***

Гарипов Р.Г. - Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча);

Бубекова Н.А. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча);

Сөләйманов Д.Т. - «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча);

Идиятов И.И.- ТР Мөслим һәм Сарман муниципаль районнары буенча МОНД һәм ПР башлыгы урынбасары (килешү буенча);

Шакиров А.А. - Татарстан Республикасы Мөслим районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының бүлек башлыгы (килешү буенча);

Гәрәев И.Р. - «Татавтодор» ААҖ Минзәлә филиалының Мөслим участогы башлыгы (килешү буенча);

Шәймәрданова Ф.Ф. - Мөслим муниципаль районының мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы;

Афзалова Р.Р. - «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры «Мөслим-информ» (килешү буенча);

Әхмәдиева Л.Р. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре (килешү буенча);

Вәлиев Ф.Ф. - «Мөслим инженерлык челтәрләре» ААҖ директоры (килешү буенча);

Идиятуллина М.С. - Мөслим районы буенча «ТР халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ бүлеге директоры (килешү буенча);

Шәймөхәммәтов М.Д.-Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль

районының «Төзекләндерү һәм яшелләндерү» ОО директоры (килешү буенча);

Сәлимгәрәев К. С. – «Мөслим РЭСы» Әлмәт электр челтәрләре «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы башлыгы (килешү буенча);

Фәтхуллина Г.Р. - Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау Министрлыгының Мөслим муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Фәттахова А.Н. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе;

Бәдертдинова Н.Н. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим туган якны өйрәнү музее» МУ директоры;

Нәбиев М.М. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мизгел» яшьләр үзәге МБУ директоры;

Мадьярова А.М. - Мөслим муниципаль районы «Үзәкләштерелгән китапханә» МБУК җитәкчесе;

Мадъяров Ш.Д. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Яшьлек» СМ» МБУ;

Мирзаянов А.Ф. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим гимназиясе» МБМУ директоры;

Әхмәтшина Ч.Т. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим лицее» МБМУ директоры;

Галиева Г.М. - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Г.Тукай исемендәге Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ директоры;

Сөнгатуллин Илгиз хәзрәт - Татарстан Республикасы Мөслим районы мөхтәсибе (килешү буенча).

Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 21 маендагы 254 номерлы карарына 2 нче кушымта

2025 ЕЛГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ЯШЬЛӘРЕНЕҢ ЯЛ ПРОГРАММАСЫ

## 1. ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2025 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ял программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе»МКУ;<br>«Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ;<br>Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| Программаның төп башкаручылары | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге;<br>«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе;<br>«Мизгел» Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>Мөслим районы буенча «ТР халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ бүлеге;<br>Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мөслим районындагы социаль яклау бүлеге<br>Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәктәптән тыш эшләү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе;<br>«Мөслим үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;<br>«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе;<br>Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Мөслим муниципаль районы буенча идарәсе;<br>Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге;<br>«ТАТМЕДИА» ААҖнең «Мөслим-информ»филиалы |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Балачакны яклау, балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итү өчен кирәкле шартлар тудыру өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру;<br>балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыру өчен шартлар тудыру;<br>тормышны яхшырту һәм балалар иминлеге проблемаларын чишү;<br>балалар һәм яшьләр ялының төрле формаларын, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү;<br>балаларның һәм яшьләрнең ял итү инфраструктурасын саклау һәм ныгыту;<br>балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2025 ел |
| Программа чаралары системасы | 1. Иҗади сәләтле яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен стационар лагерьда профильле сменалар оештыру.<br>2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге сәламәтләндерү лагерьларында сменаларны оештыру.<br>3. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру (дәүләт хакимияте органнарыннан, дәүләт органнарыннан, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш)<br>4.Каникул чорында хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыру планы |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны 2025 елга финанслауның гомуми күләме 6556,85 м.сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан ял оештыруга субсидияләр 5639,90 м.сум;<br>җирле үзидарә органнары акчаларыннан ял оештыруга субсидияләр 57,00 м.сум;<br>предприятиеләр һәм оешмалар хезмәткәрләренең балаларының ялын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2,9 м. сум;<br>ата-аналар акчалары 856,85 м.сум. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Каникул вакытында 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларны ял итүнең һәм савыктыруның төрле формалары белән тәэмин итү 34,6 процент дәрәҗәсендә.<br>Стационар һәм палаткалы лагерьларда профиль сменалар өлешен каникул вакытында төрле ял һәм сәламәтләндерү формалары белән колачланган балаларның гомуми санынннан 10,5 процентка кадәр арттыру |

## 2. ӘЛЕГЕ ПРОГРАММА КЫСАЛАРЫНДА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЛӘР КҮЛӘМНӘРЕНЕҢ РАСЛАНГАН НОРМАТИВЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР

| Чаралар атамасы | Уздыру вакыты | Кеше саны | Оештыру өчен җаваплы (башкаручы) |
|---|---|---|---|
| ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ КӨНДЕЗГЕ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ (ҖӘЙГЕ ЧОР) | 02.06.2025 - 22.06.2025 ел | 270 | . «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ; «Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ |
| ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ, ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫ, МУНИЦИПАЛЬ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ | 10.06.2025 - 30.06.2025 ел | 56 | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мизгел» ЯҮ МБУ |
| ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ БАЗАСЫНДА УКУЧЫЛАРНЫҢ КӨНДЕЗГЕ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ | 22.03.2025 - 28.03.2025 ел | 150 | «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ; «Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ |
| «УРМАН ИЛЕ»СТАЦИОНАР-СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ ЛАГЕРЕНДӘ ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНА ОЕШТЫРУ | 04.07.2025 - 21.07.2025 ел | 56 | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе. Мөслим «Мизгел» яшьләр үзәге |
| «УРМАН ИЛЕ»СТАЦИОНАР-СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ ЛАГЕРЕНДӘ ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНА ОЕШТЫРУ | 25.07.2025 - 11.08.2025 ел | 56 | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге; Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мизгел» ЯҮ МБУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ХЕЗМӘТ ҺӘМ ЯЛ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ | 02.06.2025 - 19.06.2025 ел | 120 | - ТР Мөслим муниципаль районы Мәгариф идарәсе МКУ;<br>«Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ |
| БАЛИГЪ БУЛМАГАННАРНЫ ВАКЫТЛЫЧА ЭШКӘ УРНАШТЫРУ | Июнь-август | | «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе»МКУ;<br>Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге<br>«Мөслим муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ бүлеге |
| ПАЛАТКА ТИБЫНДАГЫ ЛАГЕРЬДА «ГАЛАКТИКА БАЛАЛАРЫ» МАХСУСЛАШТЫРЫЛГАН СМЕНАЛАРЫ | Июнь-август | 5 | «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ;<br>«Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ |
| АВЫР ТОРМЫШ ХӘЛЕНДӘ БУЛГАН БАЛАЛАР ӨЧЕН СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬДА СМЕНА | Июнь-август | 15 | «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ;<br>«Мәктәптән тыш эшләү үзәге» МБУ<br>Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мөслим районындагы социаль яклау бүлеге |

### *3. ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ КӨНДЕЗГЕ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ*

| ***Лагерь оештыру өчен база (мәктәп)*** | ***Үткәрү территориясе*** | ***Кеше саны*** | ***Көн саны*** | ***Юлламаның норматив бәясе, сум.*** | ***Бюджеттан субсидияләр, сум.*** | ***Ата-ана взносы, сум.*** | ***Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет), сум.*** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ***Җәйге чорда*** | | | | | | | |
| «Мөслим урта мәктәбе» МБГББУ | Мөслим ав., Тукай ур., 21 й. | 80 | 21 | 5449,24 | 370 548,15 | 65 391,05 (817, 39) | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Мөслим гимназиясе» МБГББУ | Мөслим авылы, Кооператив ур., 170а | 80 | 21 | 5449,24 | 370 548,15 | 65 391,05 | |
| «Мөслим лицее» МБГББУ | Мөслим ав., Октябрь ур., 39 й. | 80 | 21 | 5449,24 | 370 548,15 | 65 391,05 | |
| «Михайловка урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | Михайловка ав., Гагарин ур., 1 й. | 30 | 21 | 5449,24 | 138 955,55 | 24 521,65 (817, 39) | |
| **Барлыгы** | | **270** | **21** | **5449,24** | **1 250 600,00** | **220 694,80** | |
| ***Язгы чорда*** | | | | | | | |
| ***Лагерь оештыру өчен база (мәктәп)*** | ***Үткәрү территориясе*** | ***Кеше саны*** | ***Көн саны*** | ***Юлламаның норматив бәясе, сум.*** | ***Бюджеттан субсидияләр, сум.*** | ***Ата-ана взносы, сум.*** | ***Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет), сум.*** |
| «Мөслим урта мәктәбе» МБГБУ | Мөслим | 76 | 7 | 1 816, 47 | 117 344,00 | 20 707,72 | |
| «Мөслим гимназиясе» МБГББУ | Мөслим | 37 | 7 | 1 816, 47 | 57 128,00 | 10 081,39 | |
| «Мөслим лицее» МБГББУ | Мөслим | 37 | 7 | 1 816, 47 | 57 128,00 | 10 081,39 | |
| **Барлыгы** | | **150** | | | **231 600,00** | **40 870, 50** | |

## *4. ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ, ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫ, МУНИЦИПАЛЬ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ*

| ***Стационар лагерь атамасы*** | ***Үткәрү территориясе*** | ***Лагерьны балансста тотучының исеме*** | ***Кеше саны*** | ***Көннәр саны*** | ***Юлламаның норматив бәясе, сум.*** | ***Бюджеттан субсидияләр, сум.*** | ***Ата-ана взносы, сум.*** | ***Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет, сум.*** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ***Дәүләт хакимияте органнары, дәүләт органнары, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балалары өчен муниципаль йөкләмә нигезендә*** | | | | | | | | |
| «Урман иле» стационар-савыктыру лагере | Наратасты ав. | Мөслим «Мизгел» ЯҮ МБУ | 56 | 21 | 26 771,00 | 1 274 300,00 | 224 876, 00 | |

## *5. СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬЛАРДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ*

| ***Стационар БСЛ исеме*** | ***Үткәрү территориясе*** | ***Лагерьны балансста тотучының исеме*** | ***Кеше саны*** | ***Көннәр саны*** | ***Юлламаның норматив бәясе, сум.*** | ***Бюджеттан субсидияләр, сум.*** | ***Ата-ана взносы, сум.*** | ***Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет), сум.*** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ***Муниципаль йөкләмә нигезендә*** | | | | | | | | |
| «Урман иле» стационар-савыктыру лагере | Наратасты ав. | Мөслим «Мизгел» ЯҮ МБУ | 56 | 18 | 22 017,86 | 1 048 050,00 | 184 950,16 | |
| «Урман иле»стационар-сәламәтләндерү лагере | Наратасты ав. | Мөслим «Мизгел» ЯҮ МБУ | 56 | 18 | 22 017,86 | 1 048 050,00 | 184 950,16 | |
| **Барлыгы** | | | **112** | | **44035,72** | **2 096 100,00** | **369 900, 32** | |

## *6. ХЕЗМӘТ ҺӘМ ЯЛ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ*

| ***Лагерь оештыру өчен база (мәктәп)*** | ***Үткәрү территориясе*** | ***Кеше саны*** | ***Көн саны*** | ***Юлламаның норматив бәясе, сум.*** | ***Бюджеттан субсидияләр, сум.*** | ***Ата-аналар акча взносы, сум.*** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ***Җәйге чорда*** | | | | | | |
| «Мөслим гимназиясе» МББУ | Мөслим ав.,Кооператив ур., 170 й. | 40 | 18 | 4 670, 84 | 186 833, 60 | - |
| «Мөслим урта мәктәбе» МБГББУ | Мөслим ав.,Тукай ур., 21 й. | 40 | 18 | 4 670, 84 | 186 833, 60 | - |
| «Мөслим лицее» МБГББУ | Мөслим ав.,Октябрь ур., 31 й. | 40 | 18 | 4 670, 84 | 186 833, 60 | - |
| **Барлыгы:** | | **120** | | | **560 500, 80** | **-** |

## 7. «ГАЛАКТИКА БАЛАЛАРЫ»БАЛАЛАР ӨЧЕН ПАЛАТКА ТИБЫНДАГЫ ЛАГЕРЬДА МАХСУСЛАШТЫРЫЛГАН СМЕНА

| ***Лагерь оештыру өчен база (мәктәп)*** | ***Үткәрү территориясе*** | ***Кеше саны*** | ***Көн саны*** | ***Юлламаның норматив бәясе, сум.*** | ***Бюджеттан субсидияләр, сум.*** | ***Ата-ана взносы, сум.*** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Килешү буенча | - | 5 | 7 | 11 560, 00 | 57 800, 00 | - |

## 8. АВЫР ТОРМЫШ ХӘЛЕНДӘ КАЛГАН БАЛАЛАР ӨЧЕН СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬДА СМЕНА

| ***Лагерь оештыру өчен база (мәктәп)*** | ***Үткәрү территориясе*** | ***Кеше саны*** | ***Көн саны*** | ***Юлламаның норматив бәясе, сум.*** | ***Бюджеттан субсидияләр, сум.*** | ***Ата-ана взносы, сум.*** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Килешү буенча | - | 5 | 21 | 26 780, 00 | 133 900,00 | - |
| Килешү буенча | - | 10 | 7 | 8 920.00 | 89 200, 00 | - |

## 9. БАЛАЛАРНЫҢ ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУНЫ ТӘЭМИН ИТҮГӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫ АКЧАЛАРЫННАН СУБСИДИЯЛӘР

| Күрсәткеч атамасы | Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидияләр суммасы, меӊ сум. |
|---|---|
| Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте органнары, дәүләт органнары, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре балалары арасыннан бер балага балаларның ялын оештыруны тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативы | 2,9 |